Җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында
ХӘБӘР ИТҮ

Җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт бирү проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итәбез.

<u>Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:</u>

1) Боерыкның проекты.
2) Өстәмә белешмәләр.

<u>Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм сроклары:</u>

Ачык тыңлаулар 22.10.2025 елдан 19.11.2025 елга кадәр үткәрелә һәм түбәндәге этапларны үз эченә ала:
- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;
-гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проектның экспозициясен яисә экспозицияләрен ачу;
-проект экспозициясен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

<u>Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:</u>
- үзләренә карата әлеге проектлар әзерләнгән җир кишәрлеге яисә капиталь төзелеш объекты урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүчеләр;
- шушы территориаль зона чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
- әлеге проектлар әзерләнгән җир кишәрлегенә якын җир кишәрлекләре чикләрендә даими яшәүче гражданнар;
- мондый җир кишәрлекләренең яисә аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
- әлеге проектлар әзерләнгән капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре территориясендә үткәрелә:
Лениногорск ш., Тукай ур., 7 й., 2 нче кат.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле, кадастр номеры 16:51:012903:1096 булган җир кишәрлегенә һәм кадастр номеры 16:51:013101:1697 булган капиталь төзелеш объектына карата җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт

ителгән төренә рөхсәт бирү боерыгы проекты буенча экспозицияне 2025 елның 30 октябреннән  Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенең 1 нче кабинетында түбәндәге адрес буенча ачарга:

Лениногорск шәһәре, Тукай ур., 7, 2 нче кат.

Проект экспозицияләрен үткәрү сроклары: 2021 елның 30 октябреннән 2021 елның 11 сентябренә кадәр.

Проект экспозициясе белән танышу вакыты – 9.00 дән 11.00 гә кадәр һәм 14.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр дүшәмбедән җомгага кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучыларга җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү проектына кагылышлы үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язма рәвештә, шул исәптән электрон рәвештә, ТР, Лениногорск муниципаль районы, Лениногорск шәһәре, Тукай урамы, 7 йорт, 1 нче кабинет адресы буенча кертергә яисә lenuparh@mail.ru, яисә 2025 елның 17 ноябрендә гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү барышында проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу журналына язма рәвештә яисә телдән язып кую юлы белән керетргә тәкъдим итәргә.

Язма рәвештә тәкъдим ителгән искәрмәләргә һәм тәкъдимнәргә документларның күчермәләре дә кушып бирелергә тиеш: физик затлар өчен яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга куелган һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2014 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләр нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү турында документның күчермәсе; юридик затлар өчен - ЕГРЮЛдан өземтә.

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының  архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә консультация бирүне оештырырга.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын билгеләргә:

2025 елның 17 ноябрендә 14.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Лениногорск шәһәре, Тукай ур., 7, 2 нче кат, 1 нче кабинет.

2025 елның 22 октябренә кадәр җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү боерыгы проектын рәсми сайтта түбәндәге адрес буенча: https://leninogorsk.tatarstan.ru/ «Шәһәр төзелеше» бүлегендә урнаштырырга.

Әлеге хәбәрнамәне Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында

(https://leninogorsk.tatarstan.ru), шулай ук түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендына урнаштырырга:

Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Лениногорск шәһәре, Тукай ур., 7 йорт, 2 нче кат.

Татарстан Республикасы
«Лениногорск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге башлыгы М.Н.Гирфанов